*Азбука природы*

*Табигать элифбасы*

# РУССКО-ТАТАРСКИЙ, ТАТАРСКО-РУССКИЙ СЛОВАРЬ БИОЛОГИЧЕСКИХ ТЕРМИНОВ

Книга пятая

КАЗАНЬ
ИЗДАТЕЛЬСТВО «МАГАРИФ»
2001

# РУСЧА-ТАТАРЧА, ТАТАРЧА-РУСЧА БИОЛОГИЯ ТЕРМИННАРЫ СҮЗЛЕГЕ

Бишенче китап

КАЗАН
«МӘГАРИФ» НӘШРИЯТЫ
2001

УДК 59
ББК 28.693.36я2
А-35

Составители: профессор КГУ А. Б. ХАЛИДОВ,
доцент КГУ В. И. ГАРАНИН

*Перепечатка материалов книги без ведома издательства является нарушением Закона Российской Федерации «Об авторском праве и смежных правах» и преследуется по закону.*

А-35 **Азбука природы:** Млекопитающие.— Русско-татарский, татарско-русский словарь биологических терминов. /Составители А. Б. Халидов, В. И. Гаранин.— Казань: Магариф, 2001. — 119 с.
ISBN 5-7761-0440-8

«Млекопитающие» — пятая книга из серии «Азбука природы». В ней представлены наиболее распространенные виды млекопитающих.
Словарь предназначен для учащихся средней школы, широкого круга читателей.

**БЗ — 63 — 96 — 97/98**

ISBN 5-7761-0440-8 © Издательство «Магариф», 2001

# *ОНИ НА ВСЕХ ШИРОТАХ ПЛАНЕТЫ*

Звери или млекопитающие, т. е. кормящие детенышей молоком, образующимся в особых — млечных — железах, это — одна из верхних ветвей эволюционного дерева позвоночных, вершиной которой считается вид — человек разумный. Кожа зверей не голая, как у амфибий, не покрыта чешуей или щитками, как у рептилий, или перьями, как у птиц, а покрыта шерстью. Вторично шерстный покров может отсутствовать. Как и птицы, звери — теплокровные (гомойотермные) животные, способные поддерживать постоянную температуру тела. Считается, что произошли млекопитающие от рептилий, которых постепенно потеснили, заняв все природные зоны Земли от океанов до горных систем. Три основные систематические группы млекопитающих представляют три типа или ступени размножения. Первая группа — однопроходные или яйцекладущие, вторая — сумчатые, третья — плацентарные. Однопроходные откладывают яйца, которые насиживают (утконос) или вынашивают в сумке (ехидна), а потом выкармливают детенышей молоком. Сумчатые (кенгуру, коала, вомбат, опоссумы и другие) помещают недоношенных детенышей в кожную сумку на брюхе, где те, питаясь молоком, «дозревают», хотя могут потом довольно долго пользоваться сумкой как убежищем. У плацентарных детеныши вынашиваются в матке и связаны с матерью плацентой, через которую проходит питание и обмен веществ. У одних зверей рождаются голые и слепые детеныши, которые развиваются в логове, питаясь молоком матери (напоминают «птенцовых» птиц), у других — детеныши зрячие и покрыты шерстью, они почти сразу могут передвигаться за матерью, питаясь молоком и постепенно переходя на питание основными кормами. Большинство зверей относится к первой группе, меньшинство (копытные, слоны, китообразные, зайцы) — ко второй, напоминая «выводковых» птиц.

Однопроходные — утконос, ехидна, проехидна — сохранились в Австралии, на островах Тасмания и Новая Гвинея. Сумчатых больше всего в тех же местах, но водятся они и в Южной Америке, а опоссумы добрались до Северной Америки, где живут среди молодых видов зверей и чувствуют себя неплохо. Самые крупные виды кенгуру обитают в Австралии, сумчатый медведь — коала — охраняется там в заповедни-

ках, а самый крупный из семейства хищных сумчатых — тилацин, или сумчатый волк, — видимо истреблен уже в XX веке.

Около 4500 видов зверей — 17 или 18 отрядов — относятся к высшим млекопитающим, т. е. плацентарным. Самыми примитивными из них считаются насекомоядные, три семейства которых — ежи, землеройки и кроты — представлены и в Республике Татарстан. Они живут как бы в четырех ярусах: ежи добывают пищу на поверхности земли, землеройки (которые на самом деле землю копать не могут) охотятся в лесной подстилке, крот — в почве, а водяная землеройка — кутора и водяной крот — выхухоль — могут плавать, нырять и кормиться в водоемах. Три вида из них — ушастый еж, кутора и выхухоль (возможно, исчезнувшая в РТ в 1980-х гг.) занесены в Красную книгу Республики Татарстан. Наиболее редкие насекомоядные — щелезубы сохранились только на островах Куба и Гаити. Виды древнего семейства тенрековых встречаются в Африке и на острове Мадагаскар.

Два отряда зверей — тропические шерстокрылы и населяющие весь земной шар, кроме полярных областей, рукокрылые — освоили, как птицы, воздушную среду. Крыланы — *летучие собаки и летучие лисицы — живут в тропиках и суб*тропиках от Африки до Океании и питаются плодами, летая за ними за десятки километров. Собственно летучие мыши — 18 семейств — от северных лесотундр до южных оконечностей южных материков. Большинство из 800 с лишним видов ловит летающих насекомых, используя эхолокацию, но есть летучие мыши, поедающие грызунов, мелких птиц, ящериц, рыб, питающиеся плодами, пыльцой цветов, а южно-американские десмодовые, или вампиры, — кровью крупных млекопитающих.

Отряд зверей, близкий к насекомоядным, носит название «приматы» — «первые», т. е. высшие. Сюда относятся полуобезьяны и обезьяны. Одно из семейств полуобезьян — тупайи (тупайя по-малайски — «похожий на белку») относили к насекомоядным. Все полуобезьяны — древесные животные, питающиеся плодами, листьями, цветами, корой деревьев, насекомыми, пауками, мелкими позвоночными. Многие из них — ночные. Богаче всего полуобезьяны представлены на острове Мадагаскар, остальные живут в тропиках Африки и Азии. Большинство из 50 видов включены в Красную книгу. Обезьяны также встречаются в тропиках и субтропиках Южной Америки (широконосые обезьяны), Африки и Азии (собакоподобные, или низшие узконосые обезьяны и человекоподобные приматы). Только два вида заходят в умеренные широты (макак-магот, или варварийская обезьяна, на Гибралтаре и Се-

веро-Западной Африке и японский макак). Макаки, мартышки, павианы и другие собакоголовые обезьяны известны со времен Древнего Египта. Позднее были открыты европейцами человекообразные обезьяны — гиббоны и орангутан в Юго-Восточной Азии, горилла и шимпанзе в Африке. Многие обезьяны, в том числе карликовый шимпанзе, горная горилла и орангутан занесены в Красную книгу. Последнее семейство приматов представлено в настоящее время одним видом — человек разумный, он пока не занесен в Красную книгу.

Своеобразный отряд неполнозубых с тремя семействами сохранился на юге Северной, в Центральной и Южной Америке. Броненосцы — наземные, покрытые панцирем звери, питающиеся муравьями, термитами и другими беспозвоночными, а также падалью и растительными кормами. Муравьеды лишены зубов, но имеют длинный липкий язык, с помощью которого извлекают обитателей муравейников и термитников, которых могут поглотить до 30 тысяч за день. Ленивцы — звери, приспособленные к жизни в кронах деревьев, где они висят всю жизнь спиной вниз, питаясь листьями, побегами, цветами и плодами деревьев.

Внешне похожи на броненосцев (и на еловые шишки) ящеры. Но по питанию они сходны с муравьедами: так же с помощью длинного языка заглатывают муравьев и термитов, но не в Америке, а в Африке и Азии.

В отряде хищных всего 7 семейств. К семейству волчьих, собачьих или псовых относятся наиболее известные звери, с древности связанные с человеком как его враги, затем вредители животноводства (волк), объекты охоты, поставляющие пушнину (лисица, песец), помощники человека (домашняя собака). Объекты их питания разнообразны — от лягушек и наземных птиц (енотовидная собака), даже насекомых (фенек) до мышевидных грызунов и зайцев (койот, песец, лисы), копытных (волк, гиеновая собака) и падали (шакал). Не менее известны кошачьи. Здесь и крупные кошки-пантеры (лев, леопард, тигр, ягуар), среди которых бывают и людоеды, и собственно кошки, один-два вида которых были одомашнены, когда человеку понадобились помощники в борьбе с мышами, поедавшими запасы зерна. К этой группе относятся и довольно крупные кошки, как американская пума (кугуар, горный лев) и рыси, из которых один вид водится и в РТ. Все кошки — специализированные хищники, ловкие и красивые звери. Особо стоит отметить два вида: самую «горную» кошку — ирбиса (снежного барса), охотящегося на горных копытных — козлов и баранов, и кошку с «собачьими» ногами — гепарда, догоняющего на коротких (до полукилометра) дистанциях

самых быстрых антилоп. Недаром в таких охотах в средние века гепард заменял охотничьих собак в странах ближнего Востока, Индии, Золотой Орде, Киевской Руси. Гепард обитает в саваннах Африки, полупустынях Азии, но в Средней Азии, видимо исчез. Ирбис живет в горах Центральной Азии. Небольшое — всего 8 видов — семейство медвежьих населяет северное полушарие, заходя в Индонезию и Южную Америку. Когда-то первобытный человек сталкивался с ныне исчезнувшим пещерным медведем. Сейчас самый северный и самый крупный вид медведей — белый — добывается по особым разрешениям жителями Арктического побережья и занесен в Красную книгу России. До сих пор человек встречается с бурым медведем на огромной территории от Пиренеев до Камчатки и от Аляски до Лабрадора. Во многих местах, включая РТ, этот вид или отдельные подвиды включены в Красную книгу. Третий вид медведей нашей страны — белогрудый или гималайский, распространен в горах и лесах Азии от Афганистана до Японии. В Северной Америке он замещается черным медведем. Самый редкий вид медведей — очковый — обитает в горах Южной Америки. Три других вида медведей — губач, бамбуковый медведь, или большая панда, и самый мелкий — малайский медведь — живут в Южной Азии от Индостана и Китая до Суматры и Калимантана. Мало известны у нас виды семейства виверровых — обитатели тропиков и субтропиков Африки, Южной Европы и Азии. Впрочем, кто читал «Рикки-Тикки-Тави» Р. Киплинга, вспомнит охотника на кобр — мангуста. Более известны енотовые, населяющие Америку (кроме одного азиатского вида — малой панды), особенно енот-полоскун, населяющий Северную Америку и акклиматизированный в Германии, Белоруссии, на Кавказе, в Киргизии и на Дальнем Востоке. Четыре вида семейства гиеновых распространены в Африке, и один из них доходит до Закавказья и юга Средней Азии — полосатая гиена, занесенная в Красную книгу России. Это — хищники, нападающие на мелких, а также раненых и больных крупных животных, но чаще питающиеся падалью. Бурая гиена на побережье Южной Африки подбирает «дары моря». Самая крупная — пятнистая гиена, живущая южнее Сахары, стаями нападает и на крупных копытных, даже старых львов. Особняком стоит земляной волк, который роет норы и охотится на мелких животных. Его чучело имеется в Зоологическом музее Казанского университета. Большинство хищников нашей фауны относится к семейству куньих. В РТ их 12 видов, в остальной России — еще 5 и 1 вид — медоед — был в фауне СССР. Виды куньих как бы делят между собой территорию и акваторию. У нас обыкновенная или лесная куница, охотится

на земле и на деревьях (в основном на белку), в лесу на земле охотится лесной хорь. Барсук с ним не конкурирует, питаясь мелкими животными, чаще добывая их в почве. Ласка — самая мелкая из куньих — живет в лесу и в поле, добывая мышей и полёвок в их норах, что не могут делать другие куньи. Светлый или степной хорь обитает в открытых ландшафтах и только заходит в лес. Основная его добыча — суслики и хомяки. В поймах и на болотах живет горностай. Он крупнее ласки, и главный его пищевой объект — крупная водяная полёвка. У воды и в воде ловит лягушек, рыбу, раков европейская норка, вытесненная у нас в последние десятилетия акклиматизированной американской. Здесь же кормится, не отходя далеко от воды, выдра. Недавно пришедшая к нам с юга каменная куница живет в горах и скалах. В городах она может лазать по стенкам домов и кормиться на чердаках голубями.

В Сибири лесная куница сменяется соболем, а лесной хорь на земле — колонком (к нам в РТ колонок заходит в отдельные годы). В горах Сибири колонка замещает более мелкий солонгой. На Дальнем Востоке появляется крупная тропическая куница — харза, нападающая и на мелких копытных. От целинных степей до пустынь встречается близкая к хорькам перевязка, охотящаяся на сусликов и песчанок в их норах. В тайге и тундре Евразии и Северной Америки живет росомаха, одна из крупных куньих (до 1 метра длиной), питающаяся падалью, остатками добычи волков и медведей, нападающая на молодых или раненых копытных. Самый крупный из куньих — калан — живет в северных частях Тихого океана, кормится рыбой, водорослями, морскими беспозвоночными, причем раковины моллюсков, панцири крабов и морских ежей разбивает камнями, которые может долго сохранять. Близки к хищным, а иногда включаются в этот отряд три семейства ластоногих — тюлени, ушастые тюлени и моржи. Это — хищные, вторично ушедшие в воду.

Большая группа зверей относится к копытным или близка к ним. Это непарнокопытные, или непарнопалые (тапиры, носороги, лошади), парнокопытные (нежвачные — свиньи, пекари и бегемоты, жвачные — оленьки и олени, жирафы и вилороги, козлы и бараны, быки и различные антилопы), мозоленогие (ламы и верблюды), китообразные (киты и дельфины), трубкозуб, даманы, хоботные (слоны), сирены (ламантины и дюгони). Почти все они давно используются человеком, получающим мясо, жир, шкуры, шерсть, слоновую кость и т.д. Часть из них давно одомашнена (лошадь и осел, буйвол, корова, як, коза, баран, верблюды, северный олень), других целесообразно одомашнить или организовать полувольное со-

держание (овцебык, лось, антилопы — канна, орикс и др., лошадь Пржевальского, лань, пятнистый и другие олени, слоны, ламы, дельфины и др.).

Как бы промежуточной группой между копытными и грызунами являются зайцеобразные, из двух семейств которых пищухи или сеноставки менее известны, а зайцы и кролики, наоборот, давно используются, первые как объекты спортивной охоты, вторые — и как лабораторные и как домашние животные.

Самая богатая видами группа зверей — грызуны. Это, в основном, мелкие и средних размеров зверьки, населяющие земной шар от Арктики до юга Америки и океанических островов. В этом самом большом отряде млекопитающих насчитывают около 1600 видов, т.е. 40% всех зверей мира. Самые крупные грызуны — сурки, бобры достигают длины до 1 метра, а водосвинка или капибара достигает 70 кг веса и длины до 1,5 м. Все они питаются растительными кормами, но многие не отказываются и от животной пищи. Большинство их наземные, немало роющих, много видов древесных, есть полуводные. Некоторые способны прыгая с ветки, планировать на расстояние до 60 м. Леса, особенно кроны деревьев, наиболее богато заселены грызунами в тропиках. У нас это — белка, летяга, сони. Полудревесными можно считать некоторых сонь (как орешниковая), бурундука, лесную мышовку, лесных мышей. Полёвки в лесах преимущественно, а в тундрах и степях полностью наземные. Основные экологические группы грызунов открытого ландшафта — землерои (слепыши, цокоры, слепушонки) и норники (сурки, луговые собачки, суслики, тушканчики и мышовки, песчанки, серые полёвки, хомяки и др.).

В потреблении растительной биомассы грызуны не уступают копытным, а в наших степях превосходят их. Грызуны — кормовая база многих хищников — всех псовых, большинства кошачьих, куньих, виверровых, енотовых, сов, многих соколообразных, особенно степного орла, канюков, луней, многих змей, крупных ящериц и амфибий. Ряд видов используется в пищу и человеком. Нельзя не упомянуть о роли грызунов в распространении зоонозов (болезней, связывающих диких животных и человека), таких, как туляремия, клещевые энцефалиты, геморрагические лихорадки и т. п.

Некоторые виды грызунов стали лабораторными животными (мыши и крысы, морские свинки, золотистый и джунгарский хомячки и др.). Из 75 видов млекопитающих, отмеченных на территории Республики Татарстан, 32 включены в Красную книгу Республики Татарстан.

**В. И. ГАРАНИН.**

## *БҮРЕ АУДА ЙӨРЕР БУРАНЛЫ ТӨНДӘ.*
## *ТИЕН ЯТАР ОЯСЫНДА КАРЛЫ КӨНДӘ.*

Татарстан Җир шарының урта полосасында — җәй һәм кыш була торган өлешендә урнашкан. Безнең территориядә диңгез-океан да, тропик урманнар да юк. Шуңа күрә биредә имезүче хайваннардан китлар, тюлень, морж, дельфиннар, Һиндстан һәм Африкадагы кебек, филләр, юлбарыс, арслан, жираф, маймыл, зебралар, Австралиядәге шикелле сумкалы кенгерәләр, опоссум, йомырка салып бала чыгаручы, ә үзе имезүче ехидна, үрдәкборыннар яшәми.

Берьюллылар (клоакалылар) — үрдәкборын, ехидна һәм проехидна, сумкалы җәнлекләр Австралиядә, Тасмания һәм Яңа Гвинея утрауларында яшиләр. Аларның кайбер төрләрен Көньяк Америкада да очратырга мөмкин. Ә менә опоссумнар Төньяк Америка җирләрен дә үз иткәннәр. Очкалак этләр һәм очкалак төлкеләр, Африка, Океания тропик урманнарында яшәп, җиләк-җимеш белән тукланалар, бу урманнар ярым-маймылларның күп төрле булуы белән билгеле.

Кимтешлеләр отрядына караган броненосецлар, кырмыска-ашарлар һәм иренчәкләр Американың үзәк һәм көньяк җирләрендә яшиләр. Аларның баштагы икесе кырмыска һәм термит белән тукланса, иренчәкләр гомерләрен агач ябалдашларында үткәрәләр, яфраклар, яшь ботак, чәчәк һәм төрле җимешләр белән тамак ялгыйлар.

Дөньяда 15 отрядка караган (маймыллар, ярыммаймыллар, кулканатлылар, ерткыч җәнлекләр, кимерүчеләр, тактояклылар һәм партояклылар, үлән ашаучы китлар яки сиреналар, китсыманнар, сумкалылар һ.б.) имезүчеләр бар. Аларның тугызы — элекке Союз территориясенә, алтысы безнең республикага туры килә. Шунысын да искәртик: туган як фаунасында, төрләр саны һәм биомассасы буенча, күпчелекне кимерүчеләр, аннары ерткыч җәнлекләр, алардан кала кулканатлылар һәм бөҗәк ашаучы имезүчеләр алып тора. Бездә имезүчеләрнең 80 ләп төре яши. Билгеле, алар арасында рес-

публикабызның көньяк һәм төньяк җирләренә генә хас тереклек ияләре дә бар. Әмма без бүре, төлке, поши, керпе, селәүсен кебек җәнлекләрне теләсә кайсы төбәктә очратабыз.

**Керпе.** Аны өлкәннәр генә түгел, балалар да яхшы белә. Ул катнаш урманнардагы якты урыннарда яшәргә ярата. Ана керпе июньдә дөньяга нәниләрен китерә. Керпе балалары сукыр туа, ярты айдан соң гына күзләре ачыла. Башта алар ана сөтен имеп тукланалар, аннары үзләре бөҗәк аулый башлыйлар.

Керпе — кызыклы җәнлек. Өйгә алып кайткач, ул кулга тиз иләшә, сөт һәм башка ризыктан авыз итә. Чәнечкеле «йомгак» көндезләрен күзгә әлләни чалынмас. Ә менә төнлә ул фатирның яки авыл өенең (сез дә, балалар, кайберләрегез аны асрап карагансыздыр) барлык почмакларына җитешә, кәгазь кисәгенә яки газета битенә тап булса, төн буена шуларпы чыштырдата, йокларга ирек бирми. Бу хәлгә без түзәбез. Ә тычкан халкы, керпедән куркып, йорттан чыгып кача. Чөнки алар бу чәнечкеле җан иясенең үзләренә көн күрсәтмәячәген яхшы үзләштергән.

Керпе — файдалы җәнлек. Ул төрле коңгызларны, корткыч бөҗәкләрне ашый, тычканнарны кыра, җиләк-җимешләрне дә читкә куймый, еланнарга да ташлана.

Керпе кышны тирән йокыда үткәрә. Көзге салкыннар башлану белән, ул түмгәк янында үзенә чокырчык әзерли, аның төбенә коры яфраклар түши, «юрганлык»ка шул ук яфракларны хәстәрли. Көннәрнең берендә керпе кышкы ятагына кереп чума. Ул ташландык өннәрне дә үз итә. Алары бигрәк тә әйбәт була чәнечкеле «йомгак»ка.

Яз килгәч урман урыны-урыны белән кардан ачыла, апрель ахырында — май башында керпеләр кышкы йокыдан уяналар.

Хәер, керпедән озаграк йоклаучы җәнлекләр дә бар. Әйтик, август уртасында ук ояларына кереп ятучы йомраннар апрельнең беренче ункөнлегендә генә йокыдан уяналар. Бу кимерүчеләрнең оялары иген кырларына якын калкулыкларда, тау итәкләрендә булыр.

Без малай чакта, җәй көннәрендә, һич тынгылык бирмәдек инде йомраннарга. Ояларына чиләк-чиләк су салып (инеш янәшә генә), аларны өннәреннән чыгарга мәҗбүр итә идек. Судан күбенгән йомраннар, шардай булып, көч-хәл белән өннәреннән җир өстенә чыга торганнар иде. Без аз ауламадык аларны. Янәсе, йомраннар — кырдан колхоз ашлыгын урлап

ташучылар, янәсе, алар — корткычлар. Шулайдыр, бу җан ияләренең күпме бөртек ташыганын исәпләп чыгарган галимнәр белән бәхәсләшергә җыенмыйм.

Йомран балаларын өйгә алып кайтып, аларны берничә көн шунда тота идем. Бәвелләре белән йорт эчен сасыталар иде. Әни эштән кайтып керүгә:

— Тагын шуларны өйдә тотасыңмы? Хәзер үк йомраннарыңны чыгарып җибәр!— ди торган иде.

Әниемнең таләбе катгый булгач, азат итә идем бу тоткыннарны. Әмма шуларның берсе миңа гомерлеккә тамга ясады — бармагымны тешләп (каты шеште дә ул), җөй-яра калдырды.

**Суыр** да — «йокы чүлмәге». Ниндие генә әле. Кышкы йокылары җиде айга сузыла. Алар республикабызның көньяк һәм көньяк-көнчыгыш (Баулы, Әлмәт, Лениногорск, Азнакай, Чирмешән һ.б. районнар) җирләрендәге таулы урыннарда яшиләр. Суырны байбак дип тә йөртәләр.

Мин бу җәнлекләрне Бурятиянең иксез-чиксез далаларында, сопка (тау) итәкләрендә очраттым. Биредә күп икән алар, тик исемнәре генә башкача — тарбаганнар дип йөртә аларны бурятлар. Тарбаганнар, иртән-иртүк нәкъ бер вакытта өннәреннән чыгып, ян-якларына каранлар да «тәф-тәф» итеп кычкыралар — бер-берсенә аваз салалар. Үрә катып, тораташтай баскан килеш безне күзәтәләр. Илебезнең көнчыгыш чикләрен япон самурайларыннан саклаганда, тарбаганнарны күп күрдем. Хәтта бер тапкыр итеннән дә авыз иттем. Ә менә утта кыздырып эретелгән маен күпме эчсәң дә үтләтми икән. Тарбаган (суыр) маен шифалы диләр.

Әле хәзер дә һәр җәй диярлек авылыбызга (Лениногорск районы) кайтам, суырлар яшәгән тау буйларында йөрим, әлеге сәер җәнлекләрне күзәтәм.

Элек суырларны Шөгер янында, Шушма елгасына коя торган Зубай инеше янәшәсендәге тау итәгендә генә очрата идек. Хәзер алар безнең Тукмак авылы каршындагы тауларны ошаттылар — шунда яшиләр. Күп алар. Коры кулдагы тау итәкләрендә дә бар бу җәнлекләр. Минем уйлавымча, суырлар авылыбыз тирәсенә республикабызга бик тә билгеле булган Түбән Чыршылы авылы тирәсендәге табигать һәйкәле зонасындагы колониядән күченеп килгәннәрдер. Хәзер алар безнең якта да үрчеделәр — биләмәләре һаман киңәя.

Суырларның гадәте нәкъ тарбаганнарныкы кебек: арткы аякларына басып, алгы тәпиләрен күкрәкләренә куеп, тирә-

юньгә сөрән салалар, өннәре дә нәкъ тарбаганнарныкы кебек. Алар өннәрен өч метр чамасы тирәнлектә, алты-сигез метр озынлыкта казыйлар. Чыгып йөрү өчен өстәмә тишекләре дә була. Суырлар ояларыннан көндез генә чыгалар, кояш баер алдыннан өннәренә ашыгалар.

Суыр, кышын оясында йоклаганда, җәен тәнендә туплаган мае исәбенә яши. Язын кар сулары агып, җирдә яшел үлән борын төртүгә, бу җәнлек йокысыннан уяна һәм тамак туйдырырга, арык тәненә май тупларга керешә.

**Бурсык** та кышны өнендә йокымсырап үткәрә. Әмма ул җылы көннәрдә оясыннан чыга, кышкы табигать белән хозурлана. Аның да өне суырныкыннан һич тә ким түгел — чатлы-чатлы җир асты юллары һәм өстәмә тишекләре бар. Бурсык һәр язны «өен» яңарта. Ул «йорт»ын урман эчендәге калкулыкта, коры җирдә җиткерә. Бурсыклар да, суырлар кебек, колония булып яшәргә яраталар.

**Тиен** — безнең урманнарда, бигрәк тә ылыслы урманнарда, еш очрый торган җәнлек. Билгеле, соңгы 10 — 15 елда аларның саны бик нык кимеде. Чыршы һәм нарат күркәләре уңышы булмаган елларда тиеннәр йөзләрчә чакрым ераклыктагы ылыслы урманнарга күченәләр. Җәй көннәрендә алар җиләк, гөмбә, төрле үлән белән тукланалар, хәтта чикләвек уңган елларны кышка да җыеп калдыралар. Шунысы да билгеле, тиен, җәен-көзен гөмбәләрне агач ботакларында киптереп, аларны кышлыкка әзерли.

Моннан берничә ел элек мин Казаннан ерак түгел (Идел буендагы нарат урманында урнашкан) «Төзүче» санаторий-профилакториенда ял иткән идем.

Моңа кадәр минем әле тиенне болай ук якыннан күргәнем юк иде. Матур икән үзе, «тун»ы да затлы. Пумала койрыгын аркасына салган килеш, алгы тәпиләре белән ипи кисәген тотып ашаган тиенгә сокланып озак карап тордым. Колак очларында берничә бөртек йоны тырпаеп тора. Ә күзләре — гүя ялтыравыклы төймәләр.

Биредә яшәүче тиеннәр кышын да азыкка интекми торгандыр. Чөнки ял итүчеләр «пумала койрыклар»ны һәр көн ипи, прәннек, хәтта конфет белән сыйлыйлар. Тиеннәр кешенең мәрхәмәтлелеген тиз тоеп алганнар, беркемнән дә курыкмыйлар — гел кеше тирәсендә чуалалар. Күзләре очлы икән: юл читенә куйган ризыкны тиз күрәләр. Мин бу урманда яшәүче тиеннәрнең хәле әйбәтлеген — төрле азыктан авыз

итуләрен күреп кинәндем. Шулай дигәннән, алар тәмле тамакка әверелгәннәр. Бу тиеннәр турында «ялкаулыкка чыкканнар, үзләре азык эзләмиләр» дип тә әйтәләр. Әйдә, теләсә нишләсеннәр, тик кышны гына исән-имин чыксыннар.

Кинәт ябалак-ябалак кар ява башлады. Тиен як-ягына каранды да, койрыгын бер селтәп, күздән юк булды. Димәк, ул оясына юнәлде, кар туктаганчы шунда посып утырачак.

Кышын **пошиларга** да җиңел түгел. Аяклары озын булса да, корсаклары белән тирән кар ярып, яшь усаклар утырган куелыкка юнәләләр, агач кайрысы белән тукланалар яки наратлыкта яшь үсентеләрнең башларын өзеп ашыйлар. Кыскасы, кышын «урман сыерлары»ның табыны мактанырлык түгел — такы-токыдан. Әмма, ничек кенә булмасын, алар шундый шартларда яшәргә яраклашканнар. Көч-гайрәтләре дә җитәрлек, бүрегә дә каршы тора алалар.

Поши — безнең як урманнары пәһлеваны. Мөгезләре дә чатлы-ботлы. Ул мөгезен декабрьдә ташлый. Әле ничек кенә — ике агач кәүсәсе арасына тыгып каера ул аны. Мартта яңа мөгез үстерә башлый. Май аенда ана поши бер яки ике бозау китерә.

Кешеләр пошины күптән кулга иялләштерергә тырыша. Әйтик, Кострома өлкәсенең дәүләт авыл хуҗалыгы тәҗрибә станциясендәге пошилар фермасында (ул Сумароково авылында урнашкан) бу хайваннар белән төрле сынау үткәрәләр. Поши кешене шул ягы белән җәлеп итә: ул калын карда да, язгы-көзге пычракта да җиңел йөри, көчле хайван, чыдам да. Елның теләсә кайсы вакытында поши үзенә азык таба.

Кышын **бүренең** дә хәле шәптән түгел, ләкин усал, ерткыч һәм хәйләкәр җанвар булганлыктан, ул теләсә нинди шартларда да үзенә азык таба. Бүре, күбесенчә урманда чир таратучы авыру җәнлекләрне эләктерә, йорт хайваннарына да ташлана. Әле дә күз алдымда: мин балачакта кышкы рәхимсез, буранлы төннәрнең берсендә бүреләр, абзарыбыздан җиде сарыкны эләктереп, аларны өзгәләп, кайсысының арт санын, кайсысының баш ягын бәрәңге бакчасы ызанына бер-бер артлы ташлап киткәннәр иде.

Ана бүре апрель ахырында 5 — 12 бала китерә. Атасы нәниләренә азык ташый. Аңа көненә күп чакрымнар юл үтәргә туры килә. Чөнки бу ерткычлар үзләре яшәгән тирәдә ауга йөрмиләр. Тора-бара ата һәм ана бүреләр балаларын үз «һөнәр»ләренә өйрәтәләр. Әйе, бүредән бүре туа. Бу ерткыч —

акыллы һәм хәйләкәр. Аны ачлыктан һәрчак аяклары һәм шушы сыйфатлары коткара.

* * *

«Табигать әлифбасы»ның биш китабына да йомгак ясап, шуны әйтәсем килә: безнең заманда үсемлекләрнең төрләре кими бара, бөҗәкләр, балыклар, кошлар һәм имезүчеләр дөньясы да сан ягыннан кимеделәр. Моның сәбәбе урманчылыкта һәм авыл хуҗалыгындагы үсемлекчелектә агулы химикатлар куллануга, промышленность предприятиеләренең елгаларга зарарлы, авыр металл калдыкларын агызуга, шулай итеп, тереклекне агулауга, аны һәлакәткә дучар итүгә кайтып кала. Җир йөзендә эзсез югалган төрләр азмыни?! Әйтик, Татарстан Республикасының Кызыл китабына теркәлгәннәре дә хәтсез. Алар белән сез «Мәгариф» нәшриятында басылып чыккан «Табигатьнең биш патшалыгы» дигән белешмә-китаптан тулырак танышырсыз.

«Табигать әлифбасы»ның бу бишенче китабында мин сезнең белән хушлашам, якын дусларым һәм яшь буын, киләчәк буын — экология сафлыгы өчен көрәштә үзләреннән өлеш кертер, дигән өмет белән калам.

**КАСЫЙМ ТӘХАУ,**
Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре,
журналистларның Х. Ямашев исемендәге республика
премиясе лауреаты.

Учебное издание

# РУССКО-ТАТАРСКИЙ, ТАТАРСКО-РУССКИЙ СЛОВАРЬ БИОЛОГИЧЕСКИХ ТЕРМИНОВ


Редакция естественной
и математической
литературы

Зав. редакцией
Ф. Г. ИШТИРЯКОВА

Редактор
КАСЫЙМ ТАХАУ

Художественный редактор
Р. А. САЙФУЛЛИНА

Художник обложки
В. Е. БУЛАТОВ

Технический редактор
Р. М. ГАЛИМОВА

Корректор
Т. Н. САБИРОВА

Компьютерная верстка
Г. Р. ГАЛИМЗЯНОВА

Изд. лицензия №183 от 7.04.97. Подписано в печать с оригинал-макета 26.02.2001. Формат $60\times90^1/_{16}$. Бумага книжно-журнальная. Гарнитура «Школьная». Печать офсетная. Печ. л. 7,5. Уч.-изд.л. 5,46. Тираж 6 300 экз. Заказ 46

Издательство «Магариф».
420111. Казань, ул. Баумана, 19.
Тел./факс (8432) 92-57-48.

ООО "Мастер Лайн". 420015 Казань, ул. Б. Красная, 55.